ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕТИГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ УРТА
ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2021 с. Средние Тиганы № 17

**Генераль планнан яисә Җирдән файдалану**
**һәм җирлек төзелеше кагыйдәләреннән өземтә**
**бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең**
**административ регламентын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлегенең Генераль планыннан яисә Җирдән файдалану кагыйдәләреннән өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга (Кушымта).
2. «Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 февралендәге 9 номерлы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Урта Тигәнәле авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **И.К.Хәмәтвәлиев**